| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЗНАКАЕВО АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330 Ленин урамы, 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50, 7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru кат adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 апрель 2020 ел № 14

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 26 февралендәге 26 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында (2019 елның 05 августындагы 26 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 36 номерлы карарлар редакциясендә)

2020 елның 1 мартында кабул ителгән 35-ФЗ номерлы «Ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Азнакай шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 26 февралендәге 26 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган административ регламентларга (2019 елның 05 августындагы 26 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 36 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны, муниципаль торак фонды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында

а) 2.5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гариза бирүче-гражданның гаилә составы турында документлар күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.);»;

б) 2.5 пунктының 5 пунктчасында өченче, дүртенче абзацларны төшереп калдырырга.

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондыннан торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) гариза бирүче гражданнарның гаилә составы турында документлар күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ.б.);».

1.3. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.4. Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнашытырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М. И. Солтанов